ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ______________ с. Верхний Услон КАРАР ______________

«Югары Ослан урта гомуми белем
бирү мәктәбе» МБОУ һәм «Макыл урта
гомуми белем бирү мәктәбе» МБОУ
штат расписаниесенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 21 гыйнварындагы 88-р номерлы күрсәтмәсен үтәү йөзеннән һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 79 һәм 99 статьялары, «Норматив чыгымнар эшләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 06 ноябрендәге 01/2276 номерлы һәм «Инлюзив белем бирү кысаларында норматив чыгымнар эшләү турында» 2017 елның 17 гыйнварындагы 01/68 номерлы хатлары, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен инклюзив белем кертү сәбәпле, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Югары Ослан урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБОУ һәм «Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБОУ штат расписаниесенә ишетү сәләте бозылган укучыларны укыту өчен 0,5 ставка күләмендә сурдотәрҗемә вазифасын кертергә.
2. «Югары Ослан урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБОУ һәм «Макыл урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБОУ директорларына 01.04.2017 елдан штат расписаниесенә үзгәрешләр кертергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ начальнигына йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.С. Хәкимҗанов

Әзерләде һәм бастырды
Л.В. Абрамова
5 экз.